СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

28.05.2021 № 11/3

На №__________от______________

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару һәм шәхси торак төзелеше өчен гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәрен билгеләү турында**

Җирләрдән оптимал файдалану һәм артык вакланууын булдырмау, гражданнарны җир кишәрлекләре белән тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы Тукай мунципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкны үстерү, гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, 20021 елның 9 мартындагы АП-12-75 номерлы Республика киңәшмәсе беркетмәсе нигезендә, Россия Федерациясе Җир кодексына, Татарстан Республикасы Җир кодексына, «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль законга, муниципаль берәмлек уставына таянып, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2008 елның 28 маендагы «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә җир кишәрлекләре бирү нормалары турында» 24/12 номерлы карары үз көчен югалткан, дип танырга.

2. «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарга дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрдән арендага яки милеккә бирелә торган җир кишәрлекләренең чик (максималь һәм минималь) күләмнәрен билгеләргә:

а) шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен:

- торак пункт чикләрендә (йорт яны җир кишәрлеге) - 0,1 гектардан алып 0,30 га кадәр;

- торак пункт чигеннән читтә (кыр җир кишәрлеге) - 0,1 гектардан 1,0 гектарга кадәр;

б) шәхси торак төзелеше өчен 0,1 гектардан 0,3 гектарга кадәр.

в) блоклы торак төзелеше - 0,1 гектардан 0,3 гектарга кадәр.

3. Әлеге карарның 2 пунктында каралган җир кишәрлекләренең иң чик (максималь һәм минималь) күләме гражданнарга әлеге карар үз көченә рәсми кергәннән соң бирелә торган җир кишәрлекләренә (яңадан бүлеп бирелә торган җир кишәрлекләренә) кагыла, дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның 2 пунктында каралган җир кишәрлекләренең иң чик (максималь һәм минималь) күләме гражданнарга әлеге карар кабул ителгәнче арендага бирелгән һәм гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә алар сатып алган җир кишәрлекләренә кагылмый дип билгеләргә.

5. Гражданнарның фактта файдалануында булган яисә әлеге карар үз көченә кергәнче билгеләнгән тәртиптә бирелгән җир кишәрлегенең күләме әлеге карарда каралган иң чик минималь күләмнән кимрәк яисә иң чик максималь күләмнән артып киткән очракта, әлеге җир кишәрлеге өчен аның күләме минималь яки максималь чик күләм булып тора.

6. Иң зур күләмнәрдән артып киткән җир кишәрлекләре, әгәр нормадан артып киткән җир кишәрлеге мөстәкыйль җир кишәрлеге буларак төзелә алмаса һәм кызыксынган җирдән чиктәш файдаланучылар белән килештерелгән очракта, иң чик күләмнәргә карата искәрмә булып тора.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарны Тукай районының «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

9. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе

Ф.М. Камаев